**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «СПАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ " МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**IV ЧАКЫРЫЛЫШ**

**КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ СЕССИЯ**
**КАРАР NO 1**

**Спас авылы,** **2024 елның 02 мае**

**«Җир салымы турында» 12.11.2020 ел, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге советының II сессиясенең №2 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 31.07.2023 № 389-ФЗ Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып
Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Спас авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы
Карар кабул итте:
1. «Җир салымы турында" 2020 елның 12 ноябрендәге Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге Советының II сессиясенең 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 3 Абзац 2 пункт яңа редакциядә язылсын:
-Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (күчемсез милек объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент торак төзелеше (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир участокларыннан тыш);».
2. Әлеге карар үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырылырга тиеш.
3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районының**
**«Спас авыл җирлеге"**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **А. С. Мухалев**